**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4704**
**23.08.2018**

Хаким Кубогына «Җәйге спорт сезонын ябу» шосседа велоспорт буенча шәһәр чемпионатын һәм беренчелеген үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

Яр Чаллы шәһәрендә Хаким Кубогына «Җәйге спорт сезонын ябу» шосседа велоспорт буенча шәһәр чемпионаты һәм беренчелеге үткәрелү уңаеннан, «Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 30 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ЗРТ санлы Законының 27 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 нче Карары белән расланган Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе, шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2018 елның 23 сентябрендә 9.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында Металлургическая урамы буенча Техническая урамы белән кисешкән урыннан Моторная урамына кадәрге автомобиль юлы участогында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен, юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының һәм шәһәрнең рәсми сайтларында урнаштырыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин